# Шигъри хиссиятле рәссам



**Рауза СОЛТАНОВА,**
сәнгать белгече.

Хаҗиев Мадияр Шәриф улы 1949 елда Татарстанның Саба районы, Керәнне авылында туган. 1976 елда Казан сәнгать училищесының нәкыш-педагогия бүлеген тәмамлаган. Шуннан бирле Чаллы шәһәренең 1 нче балалар сәнгать мәктәбендә эшли.

Мадияр Хаҗиев кебек, иҗаты педагогик эшчәнлек белән нәтиҗәле яраштыра алу һәрбер иҗат кешесенә дә бирелми. Аның талантлы, тәҗрибәле остаз икәнлеге мәгълүм. Шәкертләре сәнгать вузларында укый, халыкара конкурсларда призлы урыннар яулый. Мәсәлән, Японииядә балалар рәсемнәре конкурсы үткәрелгән саен Мадияр әфәндедәнен укучылары алтын медаль алмыйча калмый. Бер карасаң, адәм баласы өчен боы да җитәрлек кебек: коллегаларыныың, шәкертләренең ихтирамы, хезмәтенең алар тарафыннан танылуы. Ләкин иҗат кешесе моның белән генә канәгатьләнә алмый. Чын остаз буларак, Мадияр Хаҗиев иҗади биеклеккә көн саен күңел биреп хезмәт куйсаң гына ирешеп була, дип саный һәм шул рәвешчә күтәрелә бара. Әлегрәк, хәтта 80 нче елларда да, аның картиналарын бер генә күргәзмәгә дә алмаслар иде, мөгаен.

"Социалистик реализм"ны теше-тырнагы белән яклаучылар күп еллар дәверендә пейзаж, портрет-этюд, тыйнак натюрморт осталарын "формалистлар", "субъектив эстетлар" дигән ярлыклар тагып шактый эзәрлекләделәр. Хәтта кайбер совет рәссамнары иҗатында исән кала алган "импрессионизм" төсмерләрен котырынып тәнкыйть иттеләр. Асылда исә алар чын француз "импрессионизмы" да түгел, бәлки рәссам Коровин традицияләре чагылышы иде. 60-70 нче елларда үз халкының милли мирасына, җирле фольклорга нигезләнү дә мөмкин булмады. Кемнең дә булса иҗатында милли үзенчәлек баш калкытса, моны рәсми совет идеологиясенә каршы чыгу дип бәяләделәр. Әлеге күренешне Мәскәү андерграундының "бульдозер күргәзмәсе"нә каршылыгы белән генә чагыштырып була.

Бәхеткә, башка заманнар җитте. 90 нчы елларның 70 нче еллардан аермасы - һәр рәссамның нәкъ менә үз фикерен, үз кыйбласын, тормышка, дөньяга үз мөнәсәбәтен иркенле рәвештә чагылдыра алуында. Реализм яши, әмма ул социалистик түгел, ә тормыш чынбарлыгы, рәссам үзе тойган чынбарлык. Бу нисбәттән Мадияр Хаҗиев 90 нчы елларга рәссамнар, аеруча милли иҗатчылар өчен яңа эра - иркенле иҗат эрасы башлану вакыты дип карый.

Мин Мадияр әфәндедәнен иҗади үсешен күптәннән күзәтеп килим. Аның беренче әсәрләре 90 нчы елларның башында ук игътибарымны җәлеп итте. Алар композиция исулларының яңалыгы, милли бизәк, чигү, шәмаил кебек халык сәнгате элементларын куллану белән үзенчәлекле иде. Гомумән, бу рәссам татар халкына гына хас башка декоратив сыйфатларны нәкышттән дә эзли.

Әлбәттә, баштан ук барысы да ал да гөл иде дип әйтү дөрес булмас иде. Әлегрәк аның иҗатында стиль төрлелеге, кайвакыт тотрыксыз сурәт юклыгы да сизелде. Һәм менә җиде-сигез елдан соң Чаллы шәһәренең "Эврика" мәдәни үзәгендә Мадияр Хаҗиевның беренче шәхси күргәзмәсе ачылды. Күргәзмәне карагач, үземә нәтиҗә ясадым: рәссамның 20 елдан артык укытучы булып эшләве иҗатка омтылышын һич киметмәгән, киресенчә, талантын үстерергә ярдәм иткән икән. Нәкъ менә шушы күргәзмәдә Мадияр Хаҗиевның иҗади үсешен, фикри тирәнлеген, нәкыш техникасын камилләштерүен күрергә мөмкин иде.

Рәссамның беренче картиналары академик чынбарлык манерасында язылган, төсләр тоныкрак һәм караңгы. Ә инде хәзерге әсәрләре исә, ачык, җете төсләргә бай булулары, гомумән, күптөслелек, мәгънәви тирәнлек белән аерылып торалар. Аларда импровизация рухы, иркенле иҗат стиле яши. Замандашларыбыз образларын, туган як пейзажын тасвирлаудан фәлсәфи гомумиләштерүгә күчү тоемлана. Рәссам балачак хатирәләрен, татар авылы көнкүрешен, гади җир кешесе тормышын, заманына бәйләп кеше язмышын сурәтли. Аңа төсләрнең милли мәгънәсе ачылган, ул халык иҗатын XX гасыр Европа нәкыше яңалыклары белән үреп бирү осталыгына ирешеп килә. Шуның нәтиҗәсе буларак, ул соңгы вакытта күп кенә кызыклы картиналар язды.

Авылда, күп балалы гаиләдә туып-үскән рәссамга авыл темасы аеруча кадерле. "Печән вакыты" (1997 ел) әсәрендә томан эчендәге хатирә сыман, печән чабарга төшү иртәсе тасвирлана: ишегалдында кешеләр силуэты, җәйге иртәнең тымызык яктысы, уянып килүче табигать... "Казан - Болгар арасы" (1996 ел), "Татар арбасы" (1995 ел) - тирән мәгънәле фәлсәфи картиналар. Алар - рәссамның халкыбыз язмышы турында уйланулары. "Әнкәй догасы" (1995 ел) әсәрендә исә ягымлы, нәфис фирүзә-сирень төсләр әнкәйләр назын көчәйтеп, гади хатын-кыз образын галәм биеклегенә күтәрә.

Мадияр Хаҗиевның Габдулла Тукайга багышланган триптихы да символларга нигезләнгән. Рәсемнәрнең исемнәре дә шартлы: "Яз", "Җәй", "Көз". Биредә рәссамның максаты - шагыйрьне мәгълүм фоторәсемнәренә охшатып ясау түгел, аның рухи халәтен чагылдыру. Яшькелт-зәңгәр төсләр картинага сагыш төсмере бирсә, ачык сары, кызыл бөрчекләр күңелгә хәвеф хисе сала, гүя шагыйрьнең фаҗигале язмышына ишарәли. Әлеге өч картинаны һәрберсендә очлы аркалар, тормыш билгесе булган гөл сурәте булу берләштерә. Рәссам яссы композицияләргә стильләштерелгән милли бизәкләр, үсемлек орнаментлары ясый, алар милләт хәтеренә салынган тамгалар сыман тоела.

Мадияр Хаҗиев әсәрләрендәге шигъри хиссият, иркенле композиция рәссам иҗатының әле яңадан-яңа төсмерләр белән ачыласын вәгъдә итә.



ГУБАЕВ фотосы